**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Кукморский муниципальный район**
**СОВЕТ СЕЛО-ЧУРИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**Татарстан Республикасы**
**Кукмара муниципаль районы**
**ЮГАРЫ ЧУРА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422125, Татарстан Республикасы, Кукмара районы,
Югары Чура авылы, Мәктәп урамы, 34
тел.: (84364) 22-0-16
эл. почта: SCur.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

14 август, 2024 ел №31

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Югары Чура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түбәндәге нигезләр буенча түләп бетерү һәм (яисә) түләтү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләтүгә өметсез дип танылa:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән алып бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмалар яисә шәхси эшмәкәрләр карамагындагы бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганда, физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуны раслый торган документлар булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органыннан бирелгән бурыч суммасы турында белешмә;

б) физик затның вафат булуына бәйле рәвештә салым органнарында исәптән төшерелүе турында белешмәләр;

в) мирас алуга хокук турында таныклык бирү турында белешмәләрн булмавы хакында салым органы биргән белешмә;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән ни булганда:

а) оешманы, шәхси эшмәкәрне, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физ затны исәпкә алу урыны буенча салым органы биргән бурыч суммасы турын белешмә;

б) салым юкка чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номер турында белешмәләр;

3) әлеге карарның 1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән ниг булганда:

- 500 сумнан артмаган бурыч булу турында салым органы биргән белешм

3. «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләүгә өметсез ди тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Кукмар муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Советының 2023 елның 2 февралендәге 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренд htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукы мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникаци челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципал районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципал районы Югары Чура авылы территориясендәге мәгълүмат стендларынд бастырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы урынбасары А.Н.Афанасье